ГЛАВА ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.07.2026 г. Заинск № 04

**Кадастр номеры 16:48:060203:55 булган җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 09.07.2026 ел, № 01-09-16058 хаты нигезендә

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Баныкин урамы - «сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары)» адресы буенча урнашкан 16:48:060203:55 кадастр номерлы, мәйданы 1 944 кв.м. булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең иҗтимагый-эшлекле зонасында (О-1).

2.Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

1) Максимов С.В. - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башлыгы урынбасары;

2) И.Н. Шакиров – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

3) Агъләмов Р. В. – «Җир төзелеше бюросы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча);

4) Оборина Г.Ф. – Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе вазифаларын башкаручы (килешү буенча);

5) Кудряшов В. В. – Зәй муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча);

6) Усик О.В. – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 13 августыннан да соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Зәй шәһәре башлыгы** **Р. Г. Кәримов**